РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ БОЛЬШЕШИНАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422054, Республика Татарстан, Сабинский район,с.Большой Шинар, ул. Кооперативная, 36
тел. (84362) 41-2-11

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ШЫҢАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422054, Татарстан Республикасы, Саба районы,Олы Шыңар авылы, Кооператив урамы, 36 йорт
тел. (84362) 41-2-11

e-mail: bshin.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
25.02.2021

КАРАР
№7

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Олы Шыңар авыл җирлегенең тезекләндерү кагыйдәләренә
үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 06.11.2003 ел №131-ФЗ, "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы һәм шулай ук тезекләндерү объектларын чиста һәм тәртиптә тотуның бердәм таләпләрен булдыру, җирлек биләмәсендә тезекләндерүнең дәрәҗәсен күтәрү максатында, һәм үткәрелгән ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча Олы Шыңар авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының 10.11.2017 елда 24нче номерлы "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегендә төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында" карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегенең тезекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертергә.

1.1. 196.1 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Учреждениеләр такталарыннан һәм режим табличкаларыннан тыш, тышкы мәгълүмат чаралары, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты белән килештерелгән паспорт нигезендә һәм аңа тулысынча туры китереп урнаштырыла һәм эксплуатацияләнә.»

1.2. 198 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«198. Грунтны ачу яки юл катламнарын каплау (җир асты коммуникацияләрен салу, реконструкцияләү яки ремонтлау, свай һәм шпунтны сугу, электртапшыру, элемтә, ут баганалары урнаштыру (алмаштыру), грунтны планлаштыру, инженерлык эзләнүләре вакытында эшләү һәм башка эшләр) белән бәйле эшләр бары тик Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан бирелгән язма рөхсәт булганда гына башкарыла.»;

1.3. 199 пунктнытүбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«199. Торак пункт территориясен төзекләндерү белән бәйле Җир, тезелеш һәм ремонт эшләрен оештыру һәм үткәрү тәртибе, җир эшләрен башкаруга ордер

рәсмиләштерү һәм алу Саба муниципаль районы җирле үзидарә органнарының хокукый актларының билгеләнгән таләпләре нигезендә башкарыла»;

1.4. 200 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«200. Агач һәм куакларны кисү, тепләү яки утырту кирәк булганда, авыл җирлеге Башкарма комитетының агач кисү, тепләү яки утырту ечен рехсәтен билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерергә кирәк.»

2. Әлеге карарны “Интернет”мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга:

Авыл җирлеге башлыгы А.Г.Гарипов